СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                        КАРАР

07.09.2018          с. Шеланга          № 44-196

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советының 16.10.2017 ел, № 31-139 «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегендә Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына ярашлы рәвештә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән проектны тикшерүдә катнашу хокукын үтәү максатында,

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы Карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны халык тыңлауларына чыгарырга.

2. Расларга:

- «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе;

- «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе.

3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2018 елның 12 октябрендә 16:00 сәгатьтә ТР, Югары Ослан районы, Шеланга авылы, Октябрь урамы, 53 йорт адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга .

4. Башкарма комитетка Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге халкының килгән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

5. Әлеге карарны 2018 елның 10 сентябренә кадәр Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Шеланга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров